| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

6 июня 2024г. с.Шалты № 99

Шалты авыл җирлеге Советының 25.05.2023 № 68 «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Шалты авыл җирлеге Советының 25.05.2023 № 68 «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» (25.03.2024 № 88 үзгәрешләре белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2. 1 нче пунктны түбәндәге пунктча белән тулыландырырга:

«8) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда җирле салымнар буенча 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин